

А.И.Полежаев музеенда Ватанны саклаучылар коненә багышланган “Патриотик укулар” атналыгы старт алды. Алар vсеп килvче буында Ватанга тугрылык, ана хезмәт итәргә әзерлек, vз якташларынын тормышы һәм батырлыклары vрнәгендә яклау максатыннан оештырылган.
Чараны А.И.Полежаев музее заведующие Валентина Степановна Шведкова алып барды.
“Гафу ит мине, синен рядовоенны” исемле татар шагыйре Муса Жәлилгә һәм Әфганстан Демократик Республикасыннан Совет гаскәрләренен чыгарунын 35 еллыгына багышланган чарада Саранск шәһәре 9 нчы урта гомуми белем бирv мәктәбенен 10 нчы сыйныф укучылары һәм 22 нче урта гомуми белем бирv мәктәбенен 8 нче сыйныф укучылары катнашты.
Муса Жәлил... Бу исемне телгә алуга, кvз алдына, ниндидер, гадәттән тыш кеше килеп баса. Ул – ялкынлы шигырьләр язган шагыйрь дә, илнен азатлыгы очен корәшкән курку белмәс батыр да.
Муса Жәлил 1906 елнын 15 февралендә хәзерге Оренбург олкәсе Мостафа авылында крестьян гаиләсендә алтынчы бала булып доньяга килгән. 1922 нче елда Муса Казанга килә һәм 1923-1925 елларда Казан педагогия институтынын рабфагында укый, 1931 нче елда Мәскәv университетынын әдәбият бvлеген тәмамлый. 1939 нчы елда Жәлилне Татарстан Язучылар берлегенен житәкчесе итеп сайлыйлар. Сугышка кадәр vк бик кvп шигырьләр, жырлар, без барыбыз да яратып укыган “Хат ташучы” поэмасы, “Алтынчәч”, “Илдар” либреттолары белән vзен талантлы шагыйрь итеп таныткан Муса Жәлил, Боек Ватан сугышы башлану белән, фронтка жибәрvләрен сорый. Анын vтенече канәгатьләндерелә. 1942 елнын жәендә Волхов фронтында, дошман чолганышында калып, авыр яраланган хәлдә, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә. Әнә шулай анын лагерь тормышы башлана. Шагыйрь әсирлектә дә корәшне туктатмый. Яшерен оешмага керә, анын житәкчеләреннән берсе була, бик кvп әсирләр белән лагерьдан качу һәм партизаннарга (Белоруссия партизаннарына 500 артык әсир кушыла) барып кушылу ниятен тормышка ашырырга уйлый. Бер хыянәтче аларнын серләрен фашистларга хәбәр итә. Шуннан сон Жәлилне һәм анын иптәшләрен Моабит тормәсенә ябалар. Шагыйрь анда да туган иленә тугрылыклы булып кала. Искиткеч рухи ныклык кvрсәтә. Үлем жәзасы котеп торганда да туган илгә, халыкка тирән мәхәббәт белән, фашистларга кочле нәфрәт белдергән шигырьләр язып, аларны vзе ясаган кечкенә дәфтәрләргә теркәп бара.
Туган илгә анын ике дәфтәре кайтты. Моабит тормәсендә бер камерада утырган бельгияле Андре Тиммерманс Муса Жәлилнен гарәп имләсендә һәм “Яналиф” татар латин графикасы белән татар телендә язылган шигырь дәфтәрләрен посольсвога житкерә, ә 1953 елда Константин Симонов бу шигырьләрне рус теленә тәржемә иттерә. Аларны ботен доньяда “Моабит дәфтәрләре” дигән исем белән беләләр. Шагыйрьне vтерсәләр дә, фашистлар анын ялкынлы жырларын, кочле рухын юк итә алмады. Муса Жәлил илгә жыр булып кайтты. Муса Жәлил исемен, илебез халкы гына тvгел, ботендонья халкы горурлык белән искә ала. Анын корәше, эшчәнлеге – кыюлык һәм батырлык vрнәге.

1944 елнын 25 августында фашистлар М. Жәлилне һәм анын корәштәшләрен жәзалыйлар. Жәлилчеләр: Гайнан Кормаш (Актvбә, Казакъстан), Фоат Сәйфелмолеков (Ташкент, Үзбәкстан), Абдулла Алиш (Коек, Татарстан), Фоат Булатов (Мәләвез, Башкортстан), Муса Жәлил (Мостафа, Ырымбур олкәсе), Гариф Шабаев (Иске Турай, Башкортстан), якташыбыз Әхмәт Симаев (Усть-Рахмановка, элекке – Пенза, хәзерге - Мордовия), Абдулла Баттал (Зур Тигәнәле, Татарстан), Зиннәт Хәсәнов (Иске Кәшер, Татарстан), Әхәт Атнашев (Петропавловск, Казакъстан), Сәлим Бохаров (Галләнур Бохараев - Миякә, Башкортстан). Советлар Союзы Герое, В.И.Ленин премиясе лауреаты Муса Жәлил һәм жәлилчеләрнен батырлыгы – vлемсез.

Барысы турында А.И.Полежаев музее заведующие Валентина Степановна Шведкова, видеоролик һәм Мор-довиянен атказанган корреспонденты Наилә Халил кызы Насырова чыгышларында укучыларга житкерделәр.

Афган сугышы ветераны, вертолет экипажы командиры, капитан Александр Григорьевич Сыркин vзләренен интернациональ бурычларын Россиядән 630 000 хәрби һәм офицер (15 мене батырларча вафат), ә Мордовиядән 300 мен (2956, 68 батырларча вафат булдылар) башкарды дип сойләде.

Интернационалист сугышчыларны искә алу коне 1989 ел белән бәйле. Әлеге елнын 15 февралендә совет гаскәрләре Афганстан территориясен тулысынча калдырган. Сугыш 35 ел элек тәмамлана. Ун елга якын хәрби бәрелешләр кvп бәла-казалар һәм газаплар китерде. Ерак Афганстанда совет сугышчылары кешелекнен ин яхшы сыйфатларын кvрсәтәләр: батырлык, ныклык һәм затлылык.

Интернационалист сугышчыларны искә алу конендә без Афганстанда сугышканнарны гына тvгел, ә 30дан артык кораллы конфликтта катнашкан 1,5 миллион россиялеләрне дә искә алабыз: Россия хәрбиләре Туган илләреннән еракта vз гомерләрен биргән һәм бурычларын vтәгән батырлар.

Бу очрашу буыннан-буынга тапшырыла торган патриотизм турында белә алган укучылар очен моһим момент булды.

**Наилә НАСЫРОВА**